**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Чалпинского сельского поселения**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Чалпы авыл жирлеге**
**башкарма комитеты**

ул. Центральная, д.35, с. Чалпы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46, факс (8-5592) 35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

Узэк урамы, 35, Чалпы авылы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46, факс (8-5592)35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «23» сентябрь 2019 года №68

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар чыгарам:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Чалпы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 150 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылларында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылларында көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны вакытлыча җыю территорияләрен җыештыру, чистарту;
- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылында зиратлар өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу ;
- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылыдна янгын сүндергечләр, янгын ранецлары сатып алу;
- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылында юлларны кардан чистарту;
- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылында җәй көне территорияне чабу;

- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылында коры агачларны, куакларны кисү;

- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылында һәлак булган сугышчылар һәйкәлләрен ремонтлау (коймалар урнаштыру, буяу, агарту, эшләр өчен килешү буенча түләү);

- Чалпы авылында һәйкәл кую ( мемориаль такта ачу);

- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылына урам исемнәре язылган табличкалар ясату;

- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылына су саклагычлар кырына «Су керү тыела» дип исемләнгән табличкалар ясату һәм урнаштыру;

- "Яна ел бәйрәме", "Җиңү көне", "Сабантуй", "Өлкәннәр көне" чаралары оештыру һәм уздыру.

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы, Ленина ур., 130 йорт, Үзәк ур., 39 йорт, Чалпы авылы мәктәп бинасында, амбулатория бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында, Камышлы, Ирекле, Балан-Бүләк авыллары мәгълүмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык: А.М.Мөхәмәтшин